Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
Ислəй авыл җирлеге Советы

КАРАР

2024 елның 12 сентябре № 45/2

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Ислəй авыл җирлеге Советының 2020 елның 23 июлендəге 76/3 номерлы карарының гамəлдə булуын туктатып тору турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының 96.6 һəм 220.1 статьяларына һəм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгəрешлəр кертү, Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезлəмəлəренең гамəлдə булуын туктатып тору һəм 2024 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары үтəлеше үзенчəлеклəрен билгелəү турында» 2023 елның 2 ноябрендəге 520-ФЗ номерлы Федераль закон, Чистай муниципаль районының «Ислəй авыл җирлеге» муниципаль берəмлеге Уставы нигезендə, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Ислəй авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Ислəй авыл җирлеге Советының 2020 елның 23 июлендəге 76/3 номерлы карары белəн расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Ислəй авыл җирлеге» муниципаль берəмлегенең җирле бюджеты акчалары исəбеннəн инвестиция проектлары буенча муниципаль гарантиялəр бирү тəртибенең гамəлдə булуын 2025 елның 1 гыйнварына кадəр туктатып торырга.
2. Əлеге карарны билгелəнгəн тəртиптə бастырып чыгарырга.
3. Əлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткерелгəн) көненнəн үз көченə керə.
4. Əлеге карарның үтəлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районының Ислəй авыл җирлеге башлыгына йөклəргə.

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
Ислəй авыл җирлеге Башлыгы В.П. Чернышев